СОВЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2023 елның 20 июне № 29/6

«Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль хезмәт турында» 2020 елның 30 гыйнварындагы 42/4 номерлы Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 мартындагы 60-ФЗ номерлы федераль законнары, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 3 февралендәге 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2020 елның 30 гыйнварындагы 42/4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 03.06.2020 № 45/4, от 12.11.2020 № 3/6, от 05.02.2021 № 6/4, от 16.08.2021 № 11/3, от 13.02.2023 № 25/1 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) **1 статьяның 4 пунктында** «, сайлау комиссиясе рәисе» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) **7 статьяның 1 пунктының 5 пунктчасында** «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) **8 статьяның 1 пунктындагы 4 пунктчасында** «, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) **11 статьяның 5 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Җирле үзидарә органы җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр,

күрсәтелгән муниципаль хезмәткәрнең урынбасары, мәнфәгатьләр конфликты булдырмау максатыннан, алар тиешле вазифаны биләгән чорда әлеге җирле үзидарә органының сайлап куелган профсоюз органында муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен чагылдыра алмый»;

5) **12 статьяның 1 пунктында:**

1 пунктчаның дүртенче абзацында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктчаның икенче абзацында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктчаның өченче абзацында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктчада «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 пунктчада «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 пунктчада «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенең җирле үзидарә органнары, башка муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләре белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

8 пунктчада «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе һәм аларның җитәкчеләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

6) **12.1 статьясында:**

1 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

10 пунктның 3 пунктчасында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

7) **14 статьяда:**

түбәндәге эчтәлекле 2 пункт өстәргә:

«2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләре муниципаль хезмәткәрләрен аттестацияләү Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләре Советлары арасында төзелгән кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турындагы килешү нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Бердәм аттестация комиссиясе тарафыннан үткәрелә.»;

2 пунктны 3 пункт дип санарга.

8) **15 статьяның 2 пунктында** «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе», «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга;

9) **20 статьяның 2 пунктындагы 4 пунктчасын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган очракта), муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәтне узу чорында хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр формалаштыру һәм күрсәтелгән белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен бирү;».

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2020 елның 30 гыйнварындагы 42/4 номерлы карары белән (Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 03.06.2020 № 45/4, от 12.11.2020 № 3/6, от 05.02.2021 № 6/4, от 16.08.2021 № 11/3, от 13.02.2023 № 25/1 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган муниципаль хезмәткәрләрне аттестацияләү турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) **1 нче бүлектә:**

1 пунктта «, муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләрендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктның икенче абзацында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) **2 нче бүлектә:**

5 пунктның беренче абзацында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенең» сүзләрен төшереп калдырырга;

6 пунктның беренче абзацында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенең» сүзләрен төшереп калдырырга;

9 пунктның 4 пунктчасында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратының» сүзләрен төшереп калдырырга;

13 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

1) **3 нче бүлектә:**

15 пунктның икенче абзацында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга;

21 пунктның беренче абзацында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенең» сүзләрен төшереп калдырырга;

муниципаль хезмәткәрләрне аттестацияләү турындагы Нигезләмәнең кушымтасында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы, Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе М.Р. Гафаров